ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

16.09.2019

№ 1402/1

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын ачыклау һәм демонтажлау тәртибен раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 нчы елның 27 нче июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Реклама турында» 2006 нчы елның 13 нче мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 нчы маддәсе, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсе нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 нче елның 27 нче февралендәге “Муниципаль учреждениеләр һәм АМР җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе Нигезләмәсен раслау турында"гы 149 нчы номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын ачыклау һәм демонтажлау тәртибен кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз карамыгымда калдырам.

Җитәкче в.б. Л.Ф. Нургаянов